СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«КУАКБАШСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КУАКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 3 июле Куакбаш № 26

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 26 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 26 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

12 статьяның 5 пунктында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 статьясында каралган очракта, капиталь төзелеш объектының архитектур-шәһәр төзелеше йөзен килештерү.» абзацын түбәндәге эчтәлекле абзац белән алмаштырырга: «капиталь төзелеш объектларының архитектур-шәһәр күренешенә таләпләр.».

2.Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында хәбәр итәргә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы К. Маркс урамы 15 нче йорт - җирле үзидарә бинасы, Сходнево-Чертанлы авылында Азатлык урамындагы 5б йорт - авыл клубы бинасында, Чүте авылында Тынычлык урамы 8а йорт - авыл клубы бинасында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (htps://tatarstan.ru) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы рәисе Р.Р.Әхмәтҗанова